ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Карар*** ***Карар***

**_30.10.2025_** **Чистай шәһәре** **№ _537_**

«2026 елның беренче яртыеллыгына
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында
тәрбияләнүчеләрне кайнар туклandыруны
оештыру турында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44 номерлы Федераль закон, «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПин 2.3/2.4.3590-20 нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә: шәһәр һәм авыл мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне туклandыруны оештыру өчен тиешле шартлар тәэмин итәргә.
2. Барлык мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә кичке ашны кертеп, тыгызландырылган төшке аш белән дүрт тапкыр туклануны, шифаханә төркемнәрендә биш тапкыр туклануны оештырырга.
3. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативлары нигезендә туклану бәясен билгеләргә (2026 елга «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 15 сентябрендәге 450 номерлы карары).

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш сәгатьләре саны | Азык-төлек продуктларына, көнгә/тәрбияләнүчегә чыгымнар нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми үсеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге) | | санатор төркемнәр | |
| | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү процессы туктатылганчы |
| 3-4 | 35,24 | 44,36 | | |
| 7-12 | 140,91 | 177,47 | 182,81 | 243,77 |

4. Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасында (Н.А. Карманова) азык-төлекне үз вакытында финанслауны һәм акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп торуны тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне кайнар тукландыруга муниципаль заказ урнаштырганда заказчы булырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының (https://chistopol.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

7.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгына (О.В. Купцова) йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов